**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23нчейортЛаешш.
422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**2021елның «22 » июне** **1619 номер**

**К А Р А Р**

**Кадастр номеры 16: 24: 190501:244 булган җир кишәрлеге белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектын әзерләү турында**

Планировка структурасы элементларын бүлеп бирү, гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 42, 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә территорияне планлаштырыла торган үстерү характеристикасын һәм чиратын билгеләү максатларында карар бирәм:

1. 16:24:190501:244 кадастр номеры булган җир кишәрлеге чикләнгән территорияне планлаштыру проектын әзерләргә керешергә.
2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42 статьясы нигезендә билгеләргә.
3. Ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2021 ел ахырына кадәр билгеләргә.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга территорияне планлаштыру проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә йөкләргә.
6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**